ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘРКӘТӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
БЕРКЕТ-КЛЮЧЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

423106, БӘРКӘТӘ АВЫЛЫ,
ЛЕНИН УРАМЫ, ЙОРТ 76 "а"

тел.+7(84396)
2-64 -66
тел./факс
+7(84396) 2-64-66

423106, СЕЛО БЕРКЕТ- КЛЮЧ,
УЛИЦА ЛЕНИНА, ДОМ 76 «а»

**№14** **25.03.2021 ел**

КАРАР

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Бәркәтә авыл җирлеге Советының
2019 елның 19 сентябрендәге 127 номерлы
карары белән расланган Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә
авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда
гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Чирмешән муниципаль районының «Бәркәтә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советының 2019 елның 19 сентябрендәге 127 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә:

1) 1.7 пунктта өченче, дүртенче, бишенче абзацларны төшереп калдырырга;

2) 2.10 пунктта «Гражданнар җыены турындагы нигезләмә нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 3.7 пунктта «(вариант буларак: форма Гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә белән билгеләнә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 3.13 пунктында «(вариант буларак: форма Гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә белән билгеләнә)» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый порталында (PRAVOTATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

Бәркәтә авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Г.Х.Гайнанова